| СОВЕТ БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЯ** **КАРАР**

31 октябрь, 2019 Олы Подберезье ав. № 24

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 25 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 25 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 1 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге карарның 4 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»;

1.2. 2 пунктның 2 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фатирлар, фатирлар өлешләре;»;

1.3. 2 пунктның 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

торак йортлар, торак йортлар өлешләре;»;

1.4. Карарга түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2.1 пунктын өстәргә.

«2.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

2.1.1. 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

2.1.2. Әлеге пунктның 2.1.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын».».

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 декабрендәге 17 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 25 номерлы “Физик затлар мөлкәтенә

салым турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан , ләкин рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Олы Подберезье авыл җирлеге мәгълүматый стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы Ф.А. Чекмарев